СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17.04.2023 с. Верхний Услон № 33-449 карарына

Гражданнар билгеләгәндә (сайланганда) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле һәм шушы муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфалары исемлеген раслау турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 25.12.2008, №273-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яисә контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе турында»19.07.2017 ел N 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Советы
карар итте:

1. Гражданнар билгеләгәндә (сайланганда) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле һәм шушы муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфалары исемлеген расларга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының закон, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы Советының
2023 елның «17» апреленнән
№ 33-449 карарына
1 номерлы кушымта

Гражданнар билгеләгәндә (сайланганда) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле һәм шушы муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш Югары Ослан муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфалары исемлеге

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы урынбасары

Югары Ослан муниципаль районының Контроль-хисап Палатасы рәисе

Югары Ослан муниципаль районының даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутатлары